# Бүленгәнне бүре ашый

***«Үзен-үзе ихтирам итмәгән милләтне башка милләтләр дә ихтирам итә алмас!»***

IX гасырда яшәгән ...иясенең бу сүзләрен ...н бүгенге көндә очраклы гына искә алмадым. Хәзер, демократия шартларында, һәр милләтнең үсүе өчен мөмкинлекләр ачылды. Әмма бүгенге хәлебез, икенче төрле әйткәндә, милли тормышыбыз бер урында таптана әле. Аны мин экономика белән чагыштырып, торгынлык хәлендә дияр идем.

Бүгенге хәлебезне аңлау өчен бер фактка тукталып узуны зарури саныйм. Очраклы рәвештә ике татар картының сөйләшкәнен тыңларга туры килгәне бар. Аларның берсе таныш кеше, 70 яшен тутырган инде. Мәчеткә намазга йөри. Икенчесе дә яшь ягыннан күпкә калышмый. Болай үзләре татарча сөйләшәләр, әмма сүзләренең яртысыннан артыгы руслардан алынганнар.

Бу очраклы сөйләшү генә түгел, кызганычка каршы, безнең бүгенге чиребез. Мәчет картлары да яртылаш урысча сөйләшкәч, алардан соң килгән буыннарга ни үпкә. Сер түгел, хәзер инде татар белән татар урында ,эштә, байтак гаиләләр өендә дә урысча сөйләшә.

Моңа китергән сәбәпләр байтак. Мәктәптә татарча укыту шәһәрләрдә, хәтта күп кенә авылларда да бетерелде. Бу сәясәт элекке СССРда милләтләрнең чәчәк атуы һәм үзара якыная баруы, дигән ясалма фикердән чыгып алга сөрелде. Чынында исә бу кечкенә аз халыклы милләтләрне йотуга, бетерүгә, урыслаштыруга юнәлдерелгән политика иде. Югары уку йортларында рус телендә генә укыту милли мәктәпләрне торган саен күбрәк кысрыклап чыгарды. Бүгенге көндә 7 миллион татарның 1,3 миллионы туган телен белми. Татар балаларының 93 проценты урыс телендә белем ала.

Идел белән Урал арасындагы элекке 6 автономияле республика халкы—марилар, удмуртлар, мордвалар, чувашлар' башкортлар һәм татарлар яши. Бүгенге көндә үзләрен мөстәкыйль республика итеп игълан иткән бу җөмһүриятләрдә дә хәл бездәгедән ким түгел, хәтта артыгы да бар. Мордовия республикасында, мәсәлән, туган телләрендә белем бирә торган бер мәктәп тә сакланмаган. Татарстан территориясендә татарлар күпләп яшәүче районнарда гына алар сакланып калганнар.

Тел—милләтнең ачкычы, аның яшәешен тәэмин итүче нигез, алшарт. Бу яктан беренче адым ясалды, бүген җөмһүриятебезнең Югары Советы телләр турында закон кабул итте. Аның нигезендә татар теле дә дәүләт теле итеп игълан ителде. Бусы бер яктан һәйбәт, әмма аны практик гамәлгә ашыру кирәк. Кызганычка каршы, бу юнәлештә эш бик сүлпән алып барыла, юк дәрәҗәсендә дисәң дә була. Минем белән килешмәүчеләр табылырга мөмкин, тик бер нәрсә факт, чынбарлыкта татар теленең кулланыш сферасы элеккедән һич тә киңәйгәне күренми әле: барысы да бүгенгәчә ничек булса шулай кала килә.

Хәлне үзгәртү өчен ниләр эшләргә кирәк соң? Минемчә беренче чиратта татар телендә укытуны гамәлгә киң кертү кирәк, әйтик, шәһәр мәктәпләрендә дә элек татар класслары бар иде. Балалар бакчаларында милли группалар туплау мондый нигез булып торалар. Мондый группалар, матбугатта язылганча, бар, ләкин аларның эш нәтиҗәсе күренми—мәктәпләрдә класслар юк. Югары уку йортларында да милли группалар, факультетлар ачу зарури, чөнки ансыз ата-аналар балаларын милли группа класларга бирүдән шикләнәчәкләр.

Яшь буында милли аңны үстерүдән ата-аналар да читтә калырга тиеш түгел. Ул туган ягыңны, халкыңны, үткән тарихын белүдән башлана. Элек татарлар арасында шундый гадәт булган: бала үзенең 7 бабасын белгән, хәтере дә сакланган. Ә бу аларны механик истә калдыру гына түгел, халкыбызның, милләтебезнең үткәнен белү, милли горурлык саклау өчен гаять тә әһәмиятле.

Милли мәдәниятны үстерү, моңа киң җәмәгатьчелекне тарту да яшь буынны милли, гомуми кешелек кыйммәтләре рухында тәрбияләүгә хезмәт итәр иде.

Боларны гамәлгә ашыру өчен безгә барыннан да элек бердәмлек кирәк. Бу яктан мин үрнәк итеп яһүдләрне китерер идем. Әнә шундый бер максатка тупланмаса, Израиль дәүләте, белмим, яши алыр иде микән?! Безгә дә бүген үз мәнфәгатьләребезне кайгырту белән генә чикләнеп, үзебезгә генә бикләнеп яши торган замана түгел, милләт интересларын кайгыртыр вакыт җитте. Халык, аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, дигән. Моның шулай икәнен тормыш күп тапкырлар исбатлады инде. Киләчәктә дә шулай булмасы өчен бердәмлек зарури безгә. Шунсыз бүген чирле кеше хәлендәге милләтебезне саклау, торгызу мөмкин түгел.

**М. МӨХӘММӘТГАЛИМ.**
Норлат шәһәре.

# Киләчәккә карап

Сәнгатьне аны тудыручы кешедән аерып карап булмый. Чөнки ул табигать, кешеләр, әйберләр, вакыйгалар белән уралып яши. Киң катлам тамашачыны музейларга, күргәзмәләргә тарту—бу әле эшнең башы гына. Ә менә тамашачыны дөрес итеп тәрбияләү мөһимрәк, һәм, әлбәттә, авыррак та.

Балаларны гомуми белем бирү мәктәбендә сәнгать юнәлешендә тәрбияләү, бәлки чынлап та, азмы-күпме нидер бирәдер, әмма монда сәләтле балалар һич тә институтка керү өчен профессиональ хәзерлек алмыйлар.

«Мин бала вакытымда рәсем ясарга бик тә ярата идем, әмма безгә шөгыльләнердәй урын юк иде. Шуңа күрә мин тора-бара әкренләп бу мавыгуымны ташладым. Рәсем ясарга омтылышы булган балаларыбызның киләчәге турында уйлыйсы иде бит!» —диюче өлкән кешеләрне еш очратырга туры килә.

1960 елларда Норлатта пионерлар йорты ачылган һәм анда сынлы сәнгать студиясе эшли башлаган иде. Безнең белән ул чакта яшь энтузиаст—рәссам В. И. Павлов шөгыльләнде. Бер үк вакытта ул 3 нче мәктәптә укыта да иде. Без әле студиягә бик яратып йөри идек. Безнең арттан анда башка балалар да кызыгып йөри торганга әйләнде.

Җәйге каникуллар вакытында җитәкчебез, тәрбиячебез, дустыбыз безне Алабугага И. И. Шишкин музей-йортына, Ульяновск һәм Куйбышевтагы музейларга һәм картина галереяларына йөртте. Гаҗәеп сәяхәтләр иде ул. Без күп кенә рәсемнәр ясап кайтып күргәзмәләр оештыра идек. Аеруча сәләтле балаларга Василий Иванович майлы буяу белән киндергә ясарга да рөхсәт итә, һәм алар үзләрен чын осталар итеп хис итәләр иде.

Соңрак исә аның күп кенә шәкертләре рәссамнар булып җитештеләр һәм хәзер дә илебезнең төрле якларында эшлиләр. 9 кеше сәнгать институтларын, ә 6 сы— сәнгать училищеларын тәмамлады.

Аның кайбер элекке шәкертләренә аерым тукталасы килә.

В. И. Матросов Харьков сәнгать-промышленность институтын бик яхшыга гына тәмамлап Ижевск институтының сәнгать-графика факультетына өлкән укытучы итеп җибәрелгән иде, хәзер үзе студентларны укыта.

А. Б. Сергеев—СССР рәссамнар берлеге члены, 1988 елда Стокгольмда (Швециядә) дөньяның 90 иленнән рәссамнар катнашкан «Тынычлык һәм социаль прогресс өчен» дип исемләнгән политик плакатлар буенча халыкара конкурста катнашып беренче премияне алды.

Физик-математик фәннәр докторы Р. И. Богданов бервакыт үзенең остазына: «Василий Иванович, минем Сезгә рәхмәтем бик зур, мин бит үземнең фәнни эшләремә иллюстрацияләрне үзем ясавым белән Сезгә бурычлы, Сез бит мине каләм һәм рәссам пумаласы белән эшләргә өйрәтүче»,—диде.

Тагын бер шәкерте—В. С. Сидоров—СССР архитекторлар берлеге члены. Мондый мисаллар тагын да бар.

Мин болар хакында нигә язам дип уйлыйсыз? Районда элекке традицияләрне яңарту һәм тагын да үстерәсе килү теләге борчый мине. Нигә соң әле Норлатта бүгенге көндә эшләп килүче музыка мәктәбе үрнәгендә балалар сәнгать мәктәбе ачмыйбыз без? Ышаныгыз, шәһәрдә сәләтле балалар аз түгел, бу хакта шикләнмәскә дә мөмкин. Ә алар билгеле бер вакыттан соң шәһәребезгә һәм районыбызга танылу һәм дан китерерләр. Иң мөһиме аларның җаннарында олуг матурлык хисе үсеш алыр, шуның нәтиҗәсе буларак югары әхлаклылык, аралашу культурасы формалашыр. Ә бит бүгенге үсеп килүче яшьләргә әлеге сыйфатлар шулкадәр җитешми.

**Администрациягә олы үтенеч бар:** барлык микрорайоннардан да балаларга йөрергә уңайлы булсын өчен шәһәрнең үзәгендә бер җайлы бина табасы иде, ә укытучыларны табарга булыр. Һәрхәлдә В. И. Павлов әле бу эшне күтәреп җибәрү, оештыру һәм балалар белән дәресләр алып бару өчен кирәкле көчкә һәм энергиягә ия булган кеше.

Авыр чор хәзер, бәхәсләшмим. Ләкин әгәр киләчәк турында уйласак, үсеп килүче буынның язмышы өчен әхлакый җаваплылык тойсак, чынлап та теләсәк, бинасын да, акчасын да табарга мөмкин. Минем бу тәкъдимем игътибарсыз калмас дип ышанам.

**В. САВЕЛЬЕВ.**
Норлат шәһәре.

## Менә ичмасам, ветераннар

Казан киез-итек комбинаты үзенең алтмыш еллыгын билгеләп үтте. Һөнәрләренә гомер буе тугрылыклы булган хезмәт ветераннары белән данлы бу коллектив. Комбинатта бүген дә эшләүче өч иптәшнең хезмәт стажы илле елдан артып китә. Минҗиһан Нуруллина, әйтик, итек басуның бөтен нечкәлекләренә төшенгән, хәзер техник участок бригадиры. Рәшидә Ваһапова комбинатта 1937 елдан бирле хезмәт куя, хәзер—ОТК контролеры. Борис Константинович Кукин комбинатта 1935 елдан бирле эшли, гомер-гомергә электромонтер. Менә шундый ветераннар белән данлы комбинат.

## Училище урынына мәдрәсә

Күптән түгел Бөгелмә шәһәрендәге элекке 69 нчы авыл хуҗалыгы училищесын аның барлык уку биналары, тулай тораклары һәм чәчүлек җирләре белән бергә шактый кыйммәт бәягә Европа һәм Себер мөселманнарының Дини идарәсе сатып алды. Биредә хәзер дини уку-производство комбинаты, ягъни мәдрәсә урнашачак. Искергән биналарны төзекләндерү өчен күп акча һәм көч салу таләп ителә. Ләкин яңа мәдрәсә җитәкчеләре ремонт эшләрен һәм җиһазлар сатып алуны кыска вакытта башкарырга һәм укуларны 1993 елда ук башлап җибәрергә уйлыйлар. Булачак шәкертләрдән гаризалар керә башлады инде.

16 яшьтән 30 яшькә кадәрге егетләр биредә дин тарихын, гарәп, төрек, инглиз телләрен, информатиканы, икътисадны, базар мөнәсәбәтләре мәсьәләләрен өйрәнәчәкләр. Мәдрәсәнең максаты — динне һәм дөнья фәннәрен яхшы белүче, хәзерге заман шартларында эшли алучы кешеләр әзерләп чыгару.

**Татарстан яңалыклар агентлыгы (ТАН).**



◆◆◆

БЕЛОРУСЬ. Гродно өлкәсе Слоним районы Малая Кракотка авылында һәвәскәр рәссам һәм музыкант Ульян Иванович Грасевич яши. Инде 90 яшен тутырып килүче бу кешенең рухи яшьлегенә сокланып бетәрлек түгел.

Ульян Грасевич рәсемнәр ясау, уен коралларында уйнау, җыр белән мавыга. Ул 38 ел авыл мәктәбендә балалар укыткан, клуб директоры булган һәм бу еллар эчендә рәсем ясау белән шөгыльләнгән. Рәссам укучыларында гына түгел, бәлки оныкларында да сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли алуы өчен сөенә.

РӘСЕМДӘ: У. И. Грасевич өендә.




**Бикүле авылында яшәүче олы җизнәбез Исламгәрәй Минекаевка 50 яшь, апабыз Роза белән яшәүләренә 25 ел тула. Аларны шушы бәйрәмнәре белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Саулык-тазалык, озын гомер, көтелмәгән иксез-чиксез шатлык, куанычлар телибез.**

**Ходай насыйп итсен Сезгә,**
**Парлы тормыш гомер-гомергә**
**Илүсә белән Лилиянең**
**Шәфкатьләрен күрергә.**
**Ак бәхетләр юлдаш булсын**
**Изге теләк бездән шул сезгә.**

**Асия, Фаил, Эдуард, Чәчәк, Гөлфия.**
**Югары Норлат авылы.**

